РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« »________2025 ел №_ ___

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 05.12.2022 елның №1023 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалануның гамәлдәге законнарда каралган шартларын булдыру, аларның сакланышын, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль юлларыннан файдаланучыларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 05.12.2022 елның №1023 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә (алга таба - тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 пунктындагы 1.3.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.3. Автомобиль юлының юл буе полосалары - автомобиль юлының беренче, икенче яисә өченче категорияле полосасына якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен тәэмин итү максатларында җир

кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләре өлешләреннән) файдалануның махсус режимы, шулай ук автомобиль юлын үстерүнең перспективаларын исәпкә алып, реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, аның сакланышының нормаль шартлары билгеләнә торган территорияләр;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05